ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 512-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Ф.Ф. Баһаутдинов, Л.Р. Кадермәтова тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 512-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2291-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев, Ф.Ф. Баһаутдинов,
Л.Р. Кадермәтова тарафыннан
кертелә

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяда:

а) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләре торак пунктлар җирләрен башка категориядәге җирләрдән аерып торалар. Шәһәр һәм авыл торак пунктлары чикләре муниципаль берәмлекләр чикләрен кисеп чыга алмый яисә аларның чикләреннән чыга алмый, шулай ук гражданнарга яисә юридик затларга бирелгән җир кишәрлекләре чикләрен кисеп чыга алмый. Шәһәр йә авыл торак пунктлары чикләренең җир кишәрлекләре чикләрен кисеп чыгу ачыкланганда мондый кисеп чыгуны бетерү Россия Федерациясе Җир кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

б) 3 пунктта «торак пунктлар» сүзләрен «шәһәр һәм авыл торак пунктлары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 9 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 12 статьяда:

а) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пунктча өстәргә:

«$1^1$) дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар;»;

б) 3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3) 15 статьяның 2 пунктында «мондый җирләрдә җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләр башкару» сүзләрен «мондый җирләрдә җир асты байлыкларыннан файдалануны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 2 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2024 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
3. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пункты 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 438-ФЗ номерлы Федераль закон белән берничә Россия Федерациясе закон актына торак пунктлар, территориаль зоналар чикләренең җир кишәрлекләре чикләрен кисеп чыгуны бетерүгә, шулай ук торак пунктлар һәм территориаль зоналар чикләрен билгеләүгә һәм алар турында белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүгә кагылышлы мәсьәләләрне җайга салуга юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелде. Аерым алганда, Россия Федерациясе Җир кодексының торак пунктлар җирләре төшенчәсен һәм торак пунктлар чикләре төшенчәсен билгеләүче 83 статьясына үзгәрешләр кертелде.

Шулай ук «Табигать дәвалау ресурслары, дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчен югалтуын тану турында» 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы Федераль закон берничә закон актына үзгәрешләр кертелде. Бу үзгәрешләр табигать дәвалау ресурслары булган һәм дәвалау-сәламәтләндерү урыннары, курортлар чикләрендә урнашкан җирләрдән файдалану һәм аларны саклау мәсьәләләрен җайга салуга юнәлдерелгән. Аерым алганда, әлеге Федераль закон белән Россия Федерациясе Җир кодексының махсус сакланылучы территорияләр җирләре төшенчәсен һәм аларның составын билгеләүче 94 статьясына үзгәрешләр кертелде.

Закон проекты белән федераль законнардагы бу үзгәрешләрне Татарстан Республикасы Җир кодексында чагылдыру тәкъдим ителә.

Шулай ук закон проекты белән Татарстан Республикасы Җир кодексының запас җирләрдән файдалануны җайга салучы 15 статьясына төгәлләштерә торган үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы территориясендәге региональ һәм җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннары һәм курортлар турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 5 июнендәге 418 номерлы карарына тиешле үзгәрешләрне кертү һәм «Җирләрне республика әһәмиятендәге махсус саклanылучы территорияләр җирләренә кертү, алардан файдалану һәм аларны саклау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 23 декабрендәге 984 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану таләп ителәчәк.